СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2023 с. Сарманово № 203

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты турында»**

1 нче статья

1. 2024 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 1 389 201,0 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 389 201,0 мең сум күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум күләмендә.

2. 2025 елга һәм 2026 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2025 елга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1 412 645,5 мең сум һәм 2026 елга 1 422 780,0 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2025 елга 1 412 645,5 мең сум, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 16 700,0 мең сум, һәм 2026 елга 1 422 780,0 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 35 300,0 мең сум күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты кытлыгы 2025 елга 0,0 мең сум һәм 2026 елга 0,0 мең сум күләмендә.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 нче статья

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль эчке бурычының өске чиге 2025 елның 1 гыйнварына 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиге 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль